ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16 февраль, 2021 ел № 5/8

Башкарма комитетны административ комиссия төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру өчен вәкаләтле орган итеп билгеләү турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1, 14 статьялары, шәһәр Уставының 28 статьясы 5 өлеше нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетын (алга таба-башкарма комитет) административ комиссия төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру өчен вәкаләтле орган итеп билгеләргә.
2. Башкарма комитетка:
1) административ комиссия төзергә;
2) административ комиссия составын һәм эш регламентын расларга;
3. Шәһәр Советы Карарларын көчен югалткан дип танырга:
1) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең административ комиссиясен төзү турында» 2006 елның 6 апрелендәге 11/5 номерлы Карары;
2) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең административ комиссиясен төзү турында» 2006 елның 6 апрелендәге 11/5 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 4 октябрендәге 25/18 номерлы Карары;
3) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең административ комиссиясе эш Регламентын раслау турында» 2017 елның 24 октябрендәге 20/11 номерлы Карары;
4) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең административ комиссиясе составын раслау турында» 2020 елның 28 маендагы 39/11 номерлы Карары;

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең административ комиссиясе эш Регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 28 маендагы 39/12 номерлы Карары;

5) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 11 августындагы 41/12 номерлы Карары;

6) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 15 декабрендәге 3/4 номерлы Карары.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев